| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ |
| РЕШЕНИЕ | | КАРАР |

«25» сентябрь, 2024 ел Алабуга шәһәре № 380

**Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы территориясендә чикләнмәгән муниципаль милектәге муниципаль мөлкәтне һәм җир кишәрлекләрен аренда түләве һәм алардан файдаланган өчен пеня буенча бурычларны түләтүгә һәм исәптән чыгаруга ышанычсыз дип тану тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2022 елның 17 мартындагы 142 номерлы карарына карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 13 июлендәге 177-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советы

КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы территориясендә чикләнмәгән муниципаль милектәге муниципаль мөлкәтне һәм җир кишәрлекләрен аренда түләве һәм алардан файдаланган өчен пеня буенча бурычларны түләтүгә һәм исәптән чыгаруга ышанычсыз дип тану тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2022 елның 17 мартындагы 142 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 пунктның 1.2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. бөлгенлек (банкротлык) турында" 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданның, индивидуаль эшкуарның банкротлык процедурасын бюджетка түләүләр буенча бурыч өлешендә тәмамлау, аны түләү бурычын үтәүдән ул күрсәтелгән Федераль закон нигезендә азат ителгән;».

1.2. 1 пунктның 1.3 пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга.

1.3. 1 пунктның 1.5 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.5. штрафка тартылган яисә суд тарафыннан карар кабул ителгән җәзага

хөкем ителгәннәргә карата амнистия яисә кичерү турында актлар куллану, аның нигезендә керемнәр администраторы бюджетка түләүләр буенча бурычларны түләтү мөмкинлеген югалта;».

1.4. 1 пунктындагы 1.6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.6. «Башкарма производство турында» 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 яки 4 пунктында каралган башкарма документны түләтүчегә нигез буенча кайтарып биргәндә башкарма производствоны тәмамлау турында суд приставы-башкаручы тарафыннан карар чыгару, банкротлык турындагы эш буенча производство ачу өчен бөлгенлек (банкротлык) турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән, биш елдан артык вакыт узган булса, әгәр бурыч барлыкка килгән көннән күләме бурычлыга карата таләпләр күләменнән артмаган булса;».

1.5. 1 пунктны түбәндәге редакциядәге 1.6.1 пунктчасы белән тулыландырырга;

«1.6.1. банкротлык турындагы эштә кулланыла торган процедураларны үткәрүгә суд чыгымнарын каплау өчен җитәрлек акчалар булмау сәбәпле, бурычлыны банкрот дип тану яки банкротлык турындагы эш буенча эшне туктату турында гаризаны суд тарафыннан кире кайтару турында акт кабул ителү;»;

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны җир-мөлкәт мөнәсәбәтләре һәм табигатьтән файдалану мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Комиссия рәисе урынбасары Р.Л. Исланов